ФОМА УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ МӘКТӘБЕ УКУЧЫЛАРЫНЫҢ АЙЛЫК ГАЗЕТАСЫ

# «КӨЗГЕ»

КӨЗГЕ

МАРТ,
2018 нче ел

№7 (37)

**ҮЗЕҢ НИНДИ, КӨЗГЕҢ ШУНДЫЙ!!!**






**8—Халыкара хатын-кызлар көне**

**21— Нәүрүз бәйрәме**

## НАЗЛЫ ТУТАШ, ЗАТЛЫ ХАНЫМНАР!

Сезне язның тәүге бәйрәме - Халыкара хатын кызлар көне белән тәбрик итәбез. Хатын-кыз-ул тулы бер дөнья, аның күңеленә мәхәббәт тә, гүзәллек тә, йомшаклык та, иң көчле Ана хисләре дә, гаилә учагы жылысы да сыйган.

Бүген хатын-кызларның күпчелеге эш белән мәшгуль. Ул балалар да үстерә, йорт-җирне дә карый - аны якты һәм җылы итә, өстәвенә, карьера ясый һәм шушы мең төрле мәшәкатьләргә чумып калмыйча, үзенең нәзакәтлелеген дә саклый белә. Боларны бары тик хатын-кыз гына булдыра ала.

Сезнен тормышыгыз яхшылык һәм яктылык, мәхәббәт, якыннарыгызның күңел җылысы һәм игътибары белән тулып, йөзләрегез елмаюдан яктырып, нурлар чәчеп торса иде!

**Мәктәп администрациясе**

Хатын-кыз ул нәфис чәчәк,
Иркәне, назны сөя;
Кадер белмәгән кулларда
Хатын-кыз шиңә, көя.
Хатын-кыз ул кояш кебек
Сиңа жылысын сибә;

Олы хөрмәт күрсәтмәсәң,
Ул сула, аннан кибә.
Хатын-кыз ул ал таң кебек,
Көн башлана аңардан;
Хатын-кызны саклау кирәк -
Аннан тормыш башлана.

**Бу санда:**


| | |
|---|---|
| Бәйрәмнән фото-репортаж | 2 |
| Ялкынның даими язучысы | 3 |
| Юлда игътибарлы булыгыз! | 4 |
| «Без бергә» иҗат фестивале | 4 |
| Олимпиада нәтиҗәләре | 5 |
| Конкурслар | 5 |
| Котлыйбыз! | 6 |



3 нче март көнне 8 мартка багышланган сыйныф сәгатьләре булып утте. Башлангыч сыйныфта бәйрәм монтаж белән башланып китте.Гирфанова Р.Н әниләргә төрле ситуацияләр тәкъдим итте, әниләрнең фикерләрен тыңладылар.Шулай ук төрле ярышлар да оештырылды.

Урта звенода 5-7 сыйныфларда Садртдинова Р.Н. алып барды.Бүгенге көн кадагында торган сорауларны күтәреп чыкты ул: интернет челтәре, балаларның буш вакытларын файдалы уткәрү,гаиләдәге проблемаларның балага йогынтысы.

Чара баларның концерт номерлары белән үрелеп барды.Ә ахырда исә, әниләр бергә жырладылар һәм балалардан бүләкләр кабул иттеләр.

Өлкән сыйныфларда Ситдикова К.К. шулай ук төрле сорауларга әниләр белән җаваплар эзләде. Балаларның чыгышларыннан исә, әниләрнең күзләрендә шатлык тамчылары күрергә була иде.



## Бәйрәмнән фоторепортаж














# Якыннан танышыйк!





**Әңгәмәне бу сан өчен без ветеран укытучыбыз Хафизова Нәгыймә Нурлыгаяновна белән алып бардык.**

- Нәгыймә апа, ни сәбәпле Сез хезмәт юлыгызны ерак районда башлап җибәрдегез?

- Мин 7 нче сыйныфны тәмамлагач Минзәлә педагогия училищесына укырга кердем. 4 ел укыдым. Укып бетергәч дипломны бирмәделәр. Юллама буенча Октябрь районы Фома авылына эшкә барып урнашкач кына дипломны тапшырдылар.

- Фома авылын беренче күргәч нинди уй-тойгылар кичердегез?

-Ул вакытта Фома авылы миңа бик ялангач күренде. Ләкин авыл халкы бик әйбәт иде. Укучылар да,эти-әниләре дә тәртипле. Укытучыларны бик хөрмәт итәләр иде ул вакытта.

- Сез бу авылда төпләнеп калырмын дип уйладыгызмы?

- Һич тә уйламаган идем.

- Сезне мәктәптә кем каршы алды?

- Мине мәктәп директоры Лотфи Минегулович һәм Клара Султановна каршы алдылар.

- Сез гомере буе башлангыч сыйныф укучыларын укыттыгызмы?

- Әйе, мин 39 ел буена башлангыч сыйныф укучыларына белем һәм тәрбия бирдем.

- Беренче укыткан укучыларыгызны хәтерлисезме? Алар ничәү иде? Алар белән элемтә тотасызмы?

-

- Саннарны бик хәтерләп бетермим.Ләкин класс саен 22-28 әр бала иде ул вакытта. Ә соңгы елларда әзәю ягына китте: 10- 12, аннан инде 6-8 гә калдылар. Алар белән мин һәрвакыт элемтәдә, аннан мәктәптә үткәрелгән һәрбер чарага, һәр бәйрәмгә укытучылар безне чакыралар. Мин аларга бик рәхмәтле. Укыткан укучыларым да өйгә килеп хәлемне белеп торалар.

- .Бүгенге мәктәп тормышы белән кызыксынасызмы?

- Әйе, кызыксынып танышып торам. Мәктәпнең алдынгылар рәтендә баруы да, эшләренә зур җаваплылык белән караучы белемле алдынгы укытучыларның нәтиҗәләре белән дә горурланам.

-Әңгәмә өчен сезгә зур рәхмәт Нәгыймә апа.

- Үзегезгә дә зур рәхмәт. Алдагы тормышыгызда укымышлы, зур кешеләр булырга насыйп булсын.

**«Яшь журналистлар» төркеме.**

## Без «Ялкын» журналының даими язучылары

**Тарих эзләре**

Һәрбер кеше үз гаиләсенең җиде буынын белергә тиеш. Иң өлкән бабайга хәтле санап килгәч, мин унике буын бабамны белүемне ачыкладым! Шәҗәрәнең тамырлары Татарстанның Нурлат районы Кизләү авылына барып тоташа. Әниемнең әнисе ягыннан төзелгән бу шәҗәрә Татарстанны гына түгел, чит төбәктәге Казахстан, Ростов, Самара, Мәскәү, Ташкент, Оренбург өлкәләрендәге татарларны берләштерә. Тамырлары Кизләү авылында башланып, күбесе шунда яки район үзәгендә тупланып калган. Иң алда килә торган җиде буынның тәгәл кайсы елларда яшәгәне билгеле булмаса да, шәҗәрәнең төп башлыгы булган-Байгелди бабайның туган елы 17 гасырлар тирәсенә туры килүе мәгълүм.

Нәселебезнең кешеләре XX гасырга хәтле нинди һөнәр белән шөгылльләнүе билгесез. Алар арасында атаклы язучылар, дин галимнәре бар дип әйтә алмыйм. Ләкин уйландыра: данлыклы Кизләү мәдрәсәсендә үз заманында Утыз Имәни, Нәҗип Думави кебек танылган шәхесләр гыйлем алган. Алар арасында безнең буынның аксакаллары да, һичшиксез, булгандыр. XX- XXI гасырда гаиләләре белән бер һөнәрне үзләштерүчеләр дә байтак. Ләкин кулга каләм алып язу бер гадәти шөгыль сыман ерак тамырлардан ук килүенә шигем юк. Әгәр дә шулай булмаса , мин шәҗәрәнең унике буынын төшемдә дә күрмәс идем!

Кулга каләм төшерүчеләрнең күбесе гарәпчә матур итеп шамаилләр дә ясый белгән. Андый гарәп язулары да әбидән калган истәлекләр арасында саклана, аларның хатлары да гарәп хәрефләре белән язылып барган. Әбием олы яшендә булса да, үзенең тарихын актарырга ярата иде. Бу шәҗәрәнең күп мәгълүматы аның тупланган дәфтәрләреннән алынды. Әлбәттә, иң беренчедән җиденчегә хәтле барлык балалары билгеле булмаса да, шәҗәрә агачында сигезенче килгән Билдан бабайның ун баласы, һәм аларның балалары тәгәл билгеле. Шәҗәрәгә карасак, башлап тармакландыручы ботак XIX гасырның икенче яртысында туган Билдан бабайдан гына башланып китә. Ә нинди зур ул!

Зур нәселнең ир-егетләре дә бирешмәс булган. Бу нәселдән унга якын Билдановлар, ә килеп кушылучылар исәбе белән унбишкә якын ир-егет Бөек Ватан сугышында илен яклаган. Арасында сугыш кырында ятып калучылар бихисап. Әбиемнең әтисенең дә кабере бары тик 59 елдан соң(59!), 1999 елда гына табылган. (Шуңа да инде әбием әтисенең туганнарын ныграк белергә, эзләргә тырыша иде.) Табылу шатлыгыннан, кызлары туганнар каберен күреп, музейга истәлекләрендә алып кайтты.

Унике буынга сузылган нык агачның тамырлары бердә корымасын иде. Безнең туачак киләчәгебез бу нәсел агачын онытмаса, киләчәгендә матур итеп, үрнәк итеп төзүенә ышанам.

**Алия Гафурова, Нурлат районы Фома мәктәбе,10 нчы сыйныф укучысы («Ялкын» , апрель, 2018, 15 нче бит)**

## Юлда игътибарлы булыгыз!



23 нче март көнне укучыларның ГИБДД инспекторы Нуруллин М.И. белән очрашуы булды. Марат Ильдусович балалар белән юл кагыйдәләренә карата әңгәмә оештырды. Юл билгеләренә, светофорга, җәяүлеләр юлына нигезләнеп кагыйдәләрне искә төшерделәр. Әңгәмә бик җанлы һәм уңышлы узды. Каникул алдыннан булган бу очрашу балаларның куркынычсызлыгы өчен файдалы мәгълүмат булды.

## Чаңгы сезоны ябылды

11 нчы мартта аэропорт территориясендә узан чаңгы сезонын рәсми рәвештә ябуга багышланган район ярышларында 6 яшьтән 70 яшькәчә 1200 спорт сөюче катнашты. Ярышлар 5 дистанциядә узды. Массакүләм чарадан безнең мәктәп укучылары бертуган Вильдановлар Рәзил, һәм Рәмзил, Сөнгатуллина Рәзилә, Салахова Әдилә, Щербаков Тимур, Тагиров Булат, Сандимирова Вероника, Гайнуллин Эдуард, Хисматов Рәсим, Минегулов Илсур, Аглиуллин Аяз, Замалиев Алмаз бик теләп катнаштылар.

## Ура каникуллар!

Укучыларның язгы каникулын 26 нчы марттан 3нче апрельгә кадәр күңелле һәм файдалы үткәрү максатыннан мәктәбебездә аерым план нигезендә эш алып барылды: ял булуга карамастан, мәктәптә балаларның шат авазы тынып тормады. Күңелле мәшәкатьләре, яңа чаралар, кызыклы очрашулары белән язгы каникул үтеп тә китте. Яңа идеяләр белән рухланган, ял итеп, көч туплаган укучыларыбыздан яңа җиңүләр, уңышлар көтеп калабыз.

**23 нче март көнне, Нурлат шәһәренең Халыклар дуслыгы йортында «Без бергә» балалар халык иҗаты фестиваль – конкурсының муниципаль этабы үтте.**

Конкурста алты номинация билгеләнгән иде: хореография, халык җыры, халык җыры ансамбле, инструменталь ансамбль, әдәби уку, мода театры. Безнең укучыларыбыз Шарафутдинова Әдилә, Хисматова Зәринә һәм “Балачак” ансамбле бик уңышлы чыгыш ясадылар. Шарафутдинова Әдилә нәфис сүз буенча Г.Шәриповaның «Тормыш сәгате» шигырен сөйләде, ә “Балачак” ансамбле үз номинациясендә уңышлы чыгыш ясады..





## В Фомкине наградили учеников, получивших призовые места на олимпиадах





16 марта, в Фомкинском Доме культуры состоялось большое мероприятие.

На сцене чествовали учеников Фомкинской средней школы, завоевавших призовые места на муниципальном этапе Всероссийских и республиканских предметных олимпиад в 2017-2018 учебном году. Гости мероприятия – начальник отдела образования исполкома района Линар Маняпов, председатель Нурлатской организации профсоюза работников образования Фарида Сагирова, главы Фомкинского, Бикуловского, Биляр-Озерского сельских поселений вручили призерам Почетные грамоты отдела образования и школьную стипендию “Өмет”. Одновременно прошел и отборочный тур на районный этап республиканского конкурса «Мы вместе». Ученики состязались в номинациях «Народный вокал», «Народный танец», «Хореография», «Художественное слово», «Творческая семья». Организатором данного мероприятия выступила Фомкинская средняя школа.

# Конкурслар





Март аенда «Мирас– Татарстан Республикасының культура тарихи объектлары балалар күзлегеннән» темасы астында Республика конкурсы булып узды. Бу конкурста безнең мәктәптән 9 нчы сыйныф укучысы Нямаева Әлинә катнашу бәхетенә иреште.

“Минем кече Ватанымның парклары һәм скверлары» темасы астында икенче Республика фоторәсемнәр конкурсы оештырылды. Бу конкурска 11 нче сыйныф укучысы Әһлиуллина Әлинәнен фотолары җибәрелде. .Аңа уңышлар телибез!







## Хөрмәтле
## Сафиуллина Резеда Дамировна!

Гомер юлың пар канатлы үтсен.
Өстәлеңдә сыйлар мул булсын.
Тормыштагы кылган игелегең,
Үзеңә зур бәхет булып кайтсын.
Бик гади син, бик гүзәл син,
Бар кешегә карата.
Шуңа күрә яше-карты
Сине бердәй ярата.
Сезгә озын гомер телибез,
Куаныч, шатлык телибез.
Сабырлык, җан тынычлыгы!

## Март аенда туучы
## кадерле укучыларыбыз:

Хәйруллина Әдилә, Закиров Рәзил, Гайсина Гөлшат, Галиуллин Рәмис!

Сезнең барыгызны да чын күңелебездән туган көнегез белән тәбрик итәбез. Сезгә укуыгызда зур уңышлар, нык сәламәтлек телибез.

Озын булсын гомерегез,
Тыныч булсын күңелегез.
Бәхет чишмәләрегез мул аксын,
Зур шатлыклар белән таң атсын!

**Бу сан өчен мәктәпнең «Яшь журналист» түгәрәге әгъзалары җаваплы**

**“ К Ө З Г Е ”**
**Директор:** Сафиуллин Хәлим Салихович
***“Фома урта гомуми белем мәктәбе”*** тарафыннан гамәлгә куелды.
(423012 Нурлат районы, Фома авылы, Мәктәп урамы, 18)

Газетага нигез салынды: сентябрь, 2011
Газета уку вакытларында айга бер тапкыр чыга.
Тиражы *чикләнмәгән.*

**Баш мөхәррир**: Фәхретдинова Равидә Нәгыймовна

**Урынбасары:** Әһлиуллин Аяз Илфат улы
**Дизайнер**: Гафурова Алия
**Корректор**: Әһлиуллина Гөлүсә Дамировна
**Редколлегия**: Әһлетдинова Гөлләр, Гайнуллина Алия, Гайсина Вероника, Закирова Гөлинә, Масгутова Гөлназ, Хайруллина Әдилә, Хисматова Зәринә